## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

« 15 « 04 2025 ел № 1230

«Тукай муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 06 сентябрендәге 4049 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 12 мартындагы 149 номерлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

«Тукай муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 06 сентябрендәге 4049 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә 17 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«17 таблица

Җитәкчеләр хезмәтенә түләү төркеме, гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең башкарган эшләренең сыйфаты өчен база окладлары һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәре

| Җитәкче хезмәтенә түләү төркеме | Күләм күрсәткеченең зурлыгы (уку елы башы торышына укучылар, тәрбияләнүчеләр саны), кеше <*> | База оклады, сум | Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр, сумнар |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 - 15 | 37 000 | 8 000 |
| 2 | 16 - 50 | 39 000 | 8 000 |
| 3 | 51 - 100 | 41 000 | 9 000 |
| 4 | 101 - 200 | 42 000 | 10 000 |
| 5 | 201 - 400 | 43 000 | 11 000 |
| 6 | 401 - 600 | 44 000 | 12 000 |
| 7 | 601 - 800 | 45 000 | 12 000 |
| 8 | 801 - 1 000 | 48 000 | 12 000 |
| 9 | 1 001 - 1 200 | 49 000 | 13 000 |
| 10 | 1 201 - 1 400 | 50 000 | 14 000 |
| 11 | 1 401 - 1 800 | 50 000 | 17 000 |
| 12 | 1 801 һәм аннан күбрәк | 51 000 | 20 000 |

--------------------------------

<*> Ябык типтагы үз-үзен девиант тотучы укучылар өчен гомуми белем бирү оешмасының, җинаять-үтәтү системасының төзәтү учреждениеләре каршындагы гомуми белем бирү оешмаларының, озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы гомуми белем бирү оешмаларының, җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларының укучылар контингенты 3 коэффициенты белән исәпкә алына.
Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда яшәүче укучылар контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына.
Гомуми белем бирү оешмаларының мәктәпкәчә төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр контингенты 1,5 коэффициенты белән исәпкә алына.
Мәктәпара уку комбинатларында укучылар контингенты 0,5 коэффициенты белән исәпкә алына.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарны 3 эш көне эчендә районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев